ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 160-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 160-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 564-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7) гидротехник корылмалар, шул исәптән сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары барлыкка китерүче гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү, сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары урнаштыру, елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү өчен Россия Федерациясе Урман кодексының 9 статьясы нигезендә юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләрен бирү;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Закон проекты федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 363-ФЗ номерлы Федераль законда дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге урман кишәрлекләре гидротехник корылмалар, шул исәптән сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары барлыкка китерүче гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү, сусаклагычлар һәм бүтән ясалма су объектлары урнаштыру, диңгез һәм елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү өчен (урман кишәрлекләре юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга биреләчәк дип билгеләнгән) бирелергә мөмкин булган затлар исемлеге төгәлләштерелә.

Закон проектында «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 7 пунктына ачыклагыч үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан чыгымнар таләп итми.